КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 август г.Казань № 671

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2018 ел, 12 июль, 566 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2020 ел, 17 март, 192 нче; 2020 ел, 14 июль, 590 нчы; 2020 ел, 5 август, 656 нчы; 2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче; 2021 ел, 7 октябрь, 959 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1180 нче; 2022 ел, 12 март, 224 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1161 нче; 2023 ел, 16 июнь, 723 нче; 2023 ел, 26 сентябрь, 1185 нче; 2024 ел, 16 июль, 562 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 пунктның 3.3.26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.3.26. Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, торгызу һәм үстерү буенча чаралар күрә;

Осталар реестрын төзү һәм алып бару тәртибе бирелгән Осталар реестры турындагы нигезләмәне, халык сәнгать һөнәрләре осталарын Осталар реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибен һәм аларны Осталар реестрыннан төшереп калдыру тәртибен раслый;

халык сәнгать һөнәрләре осталарын Осталар реестрына кертү һәм аларны Осталар реестрыннан төшереп калдыру турында карар кабул итә;

халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә, шул исәптән Министрлык карамагындагы

оешмаларны җәлеп итеп, мәгълүмат системаларын алып баруны тәэмин итә;

белешмәләрне халык сәнгать һөнәрләре традицион яшәгән урыннарның дәүләт реестрына, сәнгать казанышы дип танылган халык сәнгать һөнәрләре әйберләре үрнәкләренең дәүләт реестрына җибәрә;

халык сәнгать һөнәрләре әйберләрен сәнгать казанышы дип танылган халык сәнгать һөнәрләре әйберләре үрнәкләре буларак теркәү максатларында аларны Халык сәнгать һөнәрләре буенча федераль эксперт советына тапшыра;

Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәрләре буенча сәнгать-эксперт советы составын төзи һәм раслый;

Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә халык сәнгать һөнәрләре традицион яшәгән урыннарны билгеләү турында» 2010 ел, 12 март, 130 нчы карарына, преамбуладагы «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 ел, 12 гыйнвар, ТРЗ-3 номерлы Татарстан Республикасы Законын» сүзләрен «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 2024 елның 18 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин